ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.08.2022 Олы Кайбыч ав. № 372

Хисап чорында муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән «Мәгариф дәрәҗәсе» күрсәткече составына керә торган «2 айдан 8 яшькә кадәрге балалар өчен мәктәпкәчә белем бирүнең һәркем өчен мөмкинлеге» ярдәмче күрсәткечен исәпләү өчен кирәкле белешмәләрне җыю һәм мониторинглау механизмы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының җирле үзидарә органы эшчәнлеге регламентын раслау турында

«2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясе үсешенең милли максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы, «Россия Федерациясе субъектларының иң югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 2021 елның 4 февралендәге 68 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указлары нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Хисап чорында муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән «Мәгариф дәрәҗәсе» күрсәткече составына керә торган «2 айдан 8 яшькә кадәрге балалар өчен мәктәпкәчә белем бирүнең һәркем өчен мөмкинлеге» ярдәмче күрсәткечен исәпләү өчен кирәкле белешмәләрне җыю һәм мониторинглау механизмы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының җирле үзидарә органы эшчәнлеге регламентын кушымтада каралганча расларга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы И.И. Хәмидуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы,
Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең
беренче урынбасары Э.Х.Заһидуллина

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитетының
«25» 08. 2022 №372
карарына кушымта

**Хисап чорында муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән «Мәгариф дәрәҗәсе» күрсәткече составына керә торган «2 айдан 8 яшькә кадәрге балалар өчен мәктәпкәчә белем бирүнең һәркем өчен мөмкинлеге» ярдәмче күрсәткечен исәпләү өчен кирәкле белешмәләрне җыю һәм мониторинглау механизмы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының җирле үзидарә органы эшчәнлеге регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Регламентны җайга салу предметы.

Әлеге хисап чорында муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән «Мәгариф дәрәҗәсе» күрсәткече составына керә торган «2 айдан 8 яшькә кадәрге балалар өчен мәктәпкәчә белем бирүнең һәркем өчен мөмкинлеге» ярдәмче күрсәткечен исәпләү өчен кирәкле белешмәләрне җыю һәм мониторинглау механизмы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының җирле үзидарә органы эшчәнлеге регламенты «2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясе үсешенең милли максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы «Россия Федерациясе субъектларының иң югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 2021 елның 4 февралендәге 68 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 17 июлендәге 915 номерлы карарының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 3 апрелендәге 542 номерлы карары, «Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы турында» 2009 елның 31 декабрендәге 920 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасы «Контроль» модуленең эшләү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 18 апрелендәге 361 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә эшләнгән һәм хисап чорында муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән «Мәгариф дәрәҗәсе» күрсәткече составына керә торган «2 айдан 8 яшькә кадәрге балалар өчен мәктәпкәчә белем бирүнең һәркем өчен мөмкинлеге» ярдәмче күрсәткечен исәпләү өчен кирәкле белешмәләрне җыю һәм мониторинглау өчен кирәкле түбәндәге мәгълүматларны җыю тәртибен билгели (алга таба – декомпозицияләнгән күрсәткеч):

мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү хезмәтләрен алучы 2 айдан 8 яшькә кадәрге балалар саны;

дәүләт яисә муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында урын бирү өчен исәпкә куелган 2 айдан 8 яшькә кадәрге балалар саны.

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ (алга таба - мәгариф бүлеге) Кайбыч муниципаль районындагы декомпозицияләнгән күрсәткечләрне жыю һәм мониторинглау өчен җаваплылык үзәге булып тора.

1.2. Белешмә мәгълүмат.

Әлеге регламент максатлары өчен Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының иң югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең иң югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү өчен, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 17 июлендәге 915 номерлы карарының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану методикаларын раслау турында» 2021 елның 3 апрелендәге 542 номерлы карары белән кертелгән, хисап чорында муниципаль дәрәҗәгә декомпозицияләнгән «Мәгариф дәрәҗәсе» күрсәткече составына керә торган «2 айдан 8 яшькә кадәрге балалар өчен мәктәпкәчә белем бирүнең һәркем өчен мөмкинлеге» ярдәмче күрсәткечен исәпләү өчен кирәкле белешмәләрне жыю һәм мониторинглау механизмы күрсәткечләрен исәпләү методикасында билгеләнгән терминнар кулланыла.

## 2. Исәпләү стандарты, жыю тәртибе һәм мәгълүматлар бирү

Декомпозияләнгән ярдәмче күрсәткечне исәпләп чыгару өчен түбәндәге мәгълүматлар кулланыла:

мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү хезмәтләрен алучы 2 айдан 8 яшькә кадәрге балалар саны;

дәүләт яисә муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында урын бирү өчен исәпкә куелган 2 айдан 8 яшькә кадәрге балалар саны.

Мәгариф бүлеге җаваплы хезмәткәре хисап чорында мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм җибәрү буенча хезмәтләр күрсәтүче оешмалардан югарыда күрсәтелгән күрсәткечләрне жыюны гамәлгә ашыра.

Кайбыч муниципаль районы буенча мәгълүмат Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы адресына Татарстан Республикасының электрон документлар әйләнеше бердәм ведомствоара системасында рәсми хат белән тапшырыла.

### 3. Мәгълүматларның составы, бирелү вакыты һәм рәвеше

3.1. Мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм җибәрү буенча хезмәтләр күрсәтүче әлеге оешмалар тарафыннан мәгълүмат бирү рәвеше таблицада күрсәтелгән.

Таблица

Мәктәпкәчә белем бирү хезмәтләрен алучы 2 айдан 8 яшькә кадәрге балалар саны

| № п/п | Мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә кую һәм җибәрү буенча хезмәтләр күрсәтүче әлеге оешма исеме | Үлчәү берәм леге (кеше) | Мәгълүмат бирү срогы хисап аеннан соң килүче айның 1 числосына кадәр квартал саен | дәүләт яисә муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында урын бирү өчен исәпкә куелган 2 айдан 8 яшькә кадәрге балалар саны | мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү хезмәтләрен алучы 2 айдан 8 яшькә кадәрге балалар саны |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |